| | |
|---|---|
| **СОВЕТ<br>КУЛАНГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КОЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

“27” февраль 2020 ел Колаңгы станциясе. №3

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль Районының Колаңгы авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына казначылык хезмәте күрсәтү һәм казначылык түләүләре системасы өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 479-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлеге Советының 2019 елның 31 октябрендәге 31 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

15 статьяның 14 абзацындагы «акчаларны исәпкә алу буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

46 статьяның 3 пунктындагы «түләүле һәм» сүзләрен «казначылык түләүләрен башкару турында боерыклар (алга таба - күрсәтмә) һәм» сүзләренә алмаштырырга;

46 статьяның 5 пунктында «түләүле документлар» сүзләрен «күрсәтмәләр» сүзенә алмаштырырга;

49 статьяның 2 пунктындагы 2 абзацында «кассалы» сүзен «казначылы» сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлегенең http://kulanga-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колангы авыл жирлеге башлыгы — Ф.Т.Нигматзянов